

**Алга, белем иленә!**

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми белем
мәктәбе укучыларының нәфис басмасы

**15 март, 2013 ел**
**№3**


## Әлеге санда:



**Мәктәп дәрьясында… Тәбрик итәбез! (2 нче бит)**



**Тарих сәхифәләре (2 нче бит )**



**Сәлам, Универсиада –2013! (3 нче бит)**



**Илһам канатында (4 нче бит )**

### Укытудагы соңгы яңалыклар

**Быел җәен мәктәбебездә эшләгән 40 лап укытучы Казан шәһәре Вахитов районының 139 нчы мәктәбендә Сингапур курслары үтте. Алар укытуның яңа методикасын үзләштерделәр.**

Дәресләрне үткәрүдә инновацион технологияләрдән тыш, хезмәттәшлек итеп укуның, парлап эшли белүнең, уй-фикерләр йөртеп эшләү алымнарының омтылышлы икәненә инанырга туры килде. Әлеге укыту системасының, төп үзенчәлеге балаларны бердәмлеккә, бер коллектив булып, киңәшләшеп эшләргә, бер-береңне тыңларга өйрәтә.

11-28 нче февральдә шул курсларның нәтиҗәсен күрү, киңәшләр бирү максатыннан мәктәбебезгә Сингапурдан вәкил килде. Күп кенә укытучылар ачык дәресләр бирделәр. Алар: Г.Г. Нуриева, А.Ф. Галияхметова, Л.Р. Абдуллина, Н.А. Приходько, Э.М. Нуреева, Э.Ш.Хөснетдинова, Е.В. Кофтункина, О.М. Назарова, А.Н. Сибгатуллина, Л.Ф. Опарина, А.И. Харитонова, Г.Ф.Сафина, Н.В.Броднева, О.В. Смолярова, А.Н. Сагдеева, Е.О. Пирогова.



Килгән кунака барлык дәресләрне инглиз укытучылары тәрҗемә итеп бардылар.

Бик кызыклы, уңышлы дәресләр карап, уңай нәтиҗәләрне күреп, килгән кунак канәгать булып китте.

Укытучы һөнәрен замана күзлегеннән чыгып караганда, бу һөнәр җиңел түгел, хәзерге укытучыларга сабырлык өстенә сабырлык кына теләп калырга була. Заманалар алып килгән төрле белем бирү стандартларын да үзләштереп була, ләкин гаиләдән килгән тәртипсез балаларны гына тәрбияләп бетереп булырмы дигән сорау гына борчый. Һәр гаилә үз баласына игътибарлы, ныклы терәк биреп торучы булсын иде. Әлеге укыту системасының төп үзенчәлеге балаларны бердәмлеккә, бер коллектив булып, киңәшләшеп эшләргә, бер-береңне тыңларга өйрәтә.

**Мөхәррирләр**

## Мәктәп хәбәрләре:

1. “Иң матур тел – туган тел” дип исемләнгән нәфис сүз осталары конкурсында 1 нче урынны Гөлназ Мотыйгуллина (5 М) (җитәкчесе: Ә.Х. Миннегалиева), 2 нче урынны Радик Идрисов (4 В) (җитәкчесе: Г.Г. Нуриева), 3 нче урынны Элина Вафина һәм Алсу Гиматдинова (4 Г)(җитәкчесе: Г.Р. Гарипова) яулады.

2. Ә.М. Айзатуллова «Ел укытучысы» конкурсында катнашты. «Фән дөньясында» республика конкурсында сертификатка лаек булды.

3. Л.И. Исмаилова «Лингвокультурология» конференциясендә катнашып сертификатка лаек булды.

4. “Татар кызы – 2013” шәһәр конкурсының район турында безнең мәктәптән 11 нче В сыйныфы укучысы Рәхиева Зөһрә “Иң сылу кыз” номинациясендә җиңүче булды. (Җитәкчесе: Л.М. Фәтхуллова).

## Тарих сәхифәләрендә



**“ЫШАН, ИЛЕМ, ШУШЫ АНТ СУГАРДЫ ЙӨРӘГЕМНЕҢ СОҢГЫ ТИБЕШЕН!..”**

( 15 февраль – герой-шагыйрь М. Җәлилне искә алу көне)

Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. 1913 елда Мусаның әтисе Мостафа абзый, ишле гаиләсен ияртеп, Оренбург шәһәренә күчә һәм вак-төяк сату эшләре белән шөгыльләнә башлый. 1918 елны ул туган авылына кире кайта һәм бер елдан шунда вафат була.

1922 елның көзендә М. Җәлил Казанга килә. Башта ул «Татарстан» газетасы редакциясендә эшли, ә 1923 елдан Татрабфакта укый башлый. Рабфакта төрле фәннәрнең нигезләре белән танышу, алдынгы яшьләр, язучылар арасында кайнау М. Җәлилнең фикри үсешенә һәм иҗат активлыгына уңай йогынты ясый. Газета-журналларда аның бер-бер артлы шигырьләре, мәкаләләре басыла, 1925 елда исә «Барабыз» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә.

1933-1934 елларда М. Җәлил Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли. Үзәк газеталарда эшләгән елларда ул, журналист-хәбәрче буларак, күп кенә промышленность предприятиеләренә, колхоз-совхозларга бара» халыкның .тормышы һәм хезмәте белән якыннан таныша. Болар һәммәсе аның әдәби иҗатында билгеле бер чагылыш табалар. 1934 елда шагыйрьнең күп кенә шигырьләрен эченә алган шактый зур җыентыгы («Орденлы миллионнар») басыла һәм шул ук елны «Стихи Мусы Джалиля» исеме белән сайланма шигырьләре беренче мәртәбә рус телендә чыга.

Композиторлар белән аралашу, музыка дөньясы белән тыгыз бәйләнеш тоту Җәлил иҗатында яңа үзгәрешләр туура сәбәп була: әсәрләрендә лирик җылылык, музыкальлек, нәфислек, халыкчан табигыйлек хасиятләре көчәя, җыр һәм романслар иҗат итүгә игътибар арта. «Сагыну», «Җир җиләгем», «Җырым булсын бүләгем», «Карашларың» кебек хисләрнең сафлыгы һәм тирәнлеге белән «аерылып торган шигырьләр, композиторлар тарафыннан музыкага салынып, халыкның яраткан җырларына әвереләләр. Әдипнең иҗатында бөтенләй яңа жанр-драматик поэма жанры да барлыкка килә.

«Алтынчәч» (1935-1941), «Илдар» (1940) драматик поэмалары нигезендә композитор Н. Җиһанов соңыннан үзенең атаклы опералярын иҗат итә.

М. Җәлилнең 1934-1941 еллар арасында язган лирик шигырьләре, җырлары, «Хат ташучы» (1938), «Алтынчәч» кебек поэмалары сугышка кадәрге татар совет поэзиясенең үзенчәлекле бер казанышы буларак тәкъдир ителәләр.

«Моабит дәфтәрләре» - Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләрендә шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйлануалары аша кеше рухының бөеклеге, куркусызлыгы, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына якты ышанычы, туган иленә, туган халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп зур эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә.

Моабит шигырьләре шагыйрьне әдәбиятның бөтен дөнья орбитасына алып чыкты. Бу шигырьләр, СССРдагы барлык милли телләргә тәрҗемә ителүдән тыш, инглиз, француз, испан, немец, гарәп, япон, венгр, румын, чех, корея һәм башка чит ил халыклары телләрендә дә кат-кат басылдылар.

**Мәгариф журналыннан**

## Мәктәп дәрьясында… Теләкләр!

**78 нче мәктәп укытучылары һәм укучылары туган көннәрен билгеләп үтүче укытучыларны котлый:**

**Гришина Татьяна Владимировна**
**Майорова Евгения Федоровна**
**Миннегалиева Асфира Хабировна**
**Голованова Татьяна Васильевна**
**Рәхиева Әлфия Нәзгатовна**
**Нуриева Гөлнара Гаптелфартовна**

**Бүгенгедәй гел елмаеп яшәгез,**
**Күзләрегездә нурлар сүнмәсен.**
**Йөрәгегездән чыккан яхшылыклар**
**Изгелекләр булып әйләнсен.**
**Бәхеткәегез охшаш булсын иде**
**Яңа туган ап-ак карларга.**
**Фәрештәләр кунсын иңнәрегезгә**
**Туган көнегез белән котларга!**

**Мөхәррирләр**



## УНИВЕРСИАДА ТУРЫНДА - ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

**27 августтан 2013 елгы җәйге Универсиаданың махсус контакт-үзәге эшли башлады. Хәзер чит ил халкы Универсиада турындагы мәгълүматны татар телендә дә тыңлый ала.**

Проектның төп максаты - Универсиада һәм аңа багышланган чаралар турындагы мәгълүматны мөмкин кадәр күбрәк кешегә җиткерү. Әлеге эшчәнлек вакытында тел каршылыкларыннан азат булу мөһим дип саный оештыручылар. Шуңа күрә Универсиада турында мәгълүмат бирү өч телдә - татар, рус һәм инглиз телләрендә алып барылачак. Моның өчен 8-800-550-2013 федераль номерына шалтырату да җитә.

Халык әлеге номер аша студент спорт уеннары тарихы, Универсиадада узачак спорт төрләре, спорт объектлары турында мәгълүмат ишетә алачак, дип хәбәр итәләр Универсиаданың «Казан-2013» башкарма дирекциясендә.



Проект Универсиада вакытында шулай ук бик зур эш башкарачак. Аның аша спорт уеннарының барышы, аларга билетлар сатып алу мөкинлеге, җиңүче исемнәрен белеп булыр, дип планлаштырыла. Оештыручылар фикеренчә, кунакханәләр, медицина учреждениеләре, ресторан һәм кафелар турындагы мәгълүматны да шәһәр кунаклары бик теләп һәм сөенеп кабул итәчәкләр.

**Интернет ресурстан**

## Универсиаданы каршы алырга әзер булыгыз!

**2013 елда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада тарихы Уеннарга кадәр үк башланып китә. 2008 елның 31 маенда Брюссельдә Казанның 2013 елгы җәйге Универсиаданы үткәрү хокукын яулавы игълан ителә. Халыкара студентлар спорты федерациясе (FISU) башкарма комитетының 27 әгъзасыннан 20 есе Казан өчен тавыш бирә.**

2013 елда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада бүгенге Россия тарихында беренче Универсиада, алай гына да түгел, беренче мульти-спорт чарасы булачак.

Универсиада 2013 елның 6 – 17 июль көннәрендә үтәчәк.

**Интернет ресурстан**







## 2013 елда Казанда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада миссиясе

Күпмилләтле кабатланмас мирасы булган шәһәрдә дөньяның төрле почмакларыннан килгән яшь спортчыларны җыю – Казанда үтәчәк Универсиаданың миссиясе нәкъ менә шуннан гыйбарәт. Россиядәге спорт традицияләрен дәвам итү, яшь буын спортчылар өчен яңа уңышларга ирешү өчен этәргеч ясау. Казанлыларның тормышын төрлерәк, кызыклырак, җайлырак итү. Безгә һәм балаларыбызга яраткан спорт төрләре белән шөгыльләнү, сәламәт тормыш алып бару өчен шартлар тудыру. Россиянең дөньякүләм дәрәҗәсен арттыруга лаеклы өлеш кертү.

**Интернет ресурстан**

# Илһам канатында



## Минем әнием

Минем әниемнең исеме – Гөлназ. Ул минем иң кадерле кешем.



Иртән мине иркәләп йокыдан уята, чәй эчертеп мәктәпкә озата. Өйгә бирелгән дәресләрне тикшерә. Үзем аңламаган сорауларга җавапны әнием һәрчак белә. Әнием эштән арып кайтса да, мина вакыт таба. Ул хастаханәдә эшли. Ул эшен бик яратып башкара. Хезмәттәшләре дә, авырулар да аны хөрмәт итәләр. Фельдшер–лаборантның эше җаваплы. Дөрес ясалган анализлар табибларга авыруларны дәвалау өчен бик кирәк.

Әнием өйдә матур гөлләр үстерә. Аның бакча чәчәкләре кар яуганчы шау итеп утыралар. Пешергән камыр ризыклары да, ашлары да телеңне йотарлык була.

Без һәрчак гаиләбез белән бергәләшеп чәй эчәргә яратабыз. Мин әниемне бик тә яратам.

**Илгиз Якубов**
**5 нче “А” сыйныфы укучысы**

## Минем әтием

Минем әтием төзүче булып эшли. Ул матур- матур өйләр төзи. Аның эше авыр булса да, тырышып эшләве дөньяга яңа, зур биналар барлыкка тудыра.

Әтием универсиадага күп өйләр һәм кибетләр төзеде. Мәсәлән, быел бакчада үзебезгә йорт салды. Әти күп эшен үзе эшләде. Ул яшь чактан ук төзүче булып эшләгән, бәлки шуңадыр аның кулы һәр эшкә дә ята.

Мәктәпкә дә әтине еш чакыралар, ул анда берәр әйбер ватылса, ясап бирә, төзәтә.

Мин әтиемне яратам !

**Алсу Әхмәдуллина**
**5 нче “Г” сыйныфы укучучысы**



## Әтиемә

Әтиебез, безнең кадерлебез,
Без бәхетле җирдә син барга.
Фәрештәләр кунсын иңнәреңә
Ирләр көне белән котларга
Дөньядагы һәрбер яхшылыктан
Өлеш чыксын сиңа мул гына
Без телибез сиңа ак бәхетләр,
Шатлыкларга илткән юл гына .
Төрле чакны күргәнсеңдер, әти,
Йөрәгеңдә күптер яра да.
Киңәшчебез, терәгебез булып,
Озак яшә безнең арада.

**Радик Идрисов**
**4 нче “В” сыйныфы укучысы**

## Әтием

Минем сезгә, үземнең әтием турында сөйләп китәсем килә. Әтиемнең исеме - Валерий. Минем әтием төзүче булып эшли. Әтием үзенең эшен бик ярата.

Ял вакытларында ул үзен бөтенләе белән безгә, ягъни гаиләгә багышлый. Бергәләп уйныйбыз да, өй эшләрен дә карыйбыз. Аның дуслары да аны хөрмәт итәләр.

Мин әтиемне бик яратам!

**Гөлмирә Батталова**
**5 нче “Г” сыйныфы укучысы**

## Табигать һәм кеше

Табигать һәм кеше. Алар аерылгысыз. Табигатьсез кеше тормышын, яшәү рәвешен күз алдына китереп булмый. Кешедән башка табигать гаҗәеп матурлыкка ия булмас иде. Фәнис Яруллин да: “Кеше табигатьне, табигать кешене бизи... Бу ике көчне аерып карап булмый. Кеше табигать матурлыкларыннан аз гына вакыттка аерылып торса да ямансулый, сагына башлый” ди.

Табигатебезнең һәр ел фасылы үзенчә гүзәл. Аның кышкы аклыгы, энҗедәй кар бөртекләренең тирбәлеп җиргә төшүе кешедә соклану хисләре уятмыйча калмый, ә саф һавасы барыбызга да шифалы. Язгы көннәрне яшькелт җөреләре, ачылып килүче чәчәкләре, күчмә кошларның куанып сайраулары белән матур. Сирень, шомырт чәчәкләренең хуш исләре бервакытлы гына. Кем генә, бу куаклар чәчәк атканда, яннарында тукталып, рәхәтлеккә чумып тормый икән! Җәйнең җиләс тә, кояш кыздырган көннәрен дә; салават күпере балкытып яуган йомшак, шифалы яңгырлары да күңелләргә хуш килә. Габдулла Тукаебыз әйтмешли бездә “Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява”. Мең төрле чәчәкләр, үләннәр үскән болын-кырларыбызда йөрүләр нинди рәхәт! Ә инде алтын көзне , зәңгәр күктә тезелеп очкан торна-казларны күз алдына китерсәк, талантлы рәссамнарыбызның ясап куйган пейзажлары диярсең. Көзен сибәләп торган яңгырлары, бер яктан эчне пошырса да; икенче яктан уҗымнарыбызны, сугару җирләрен уңдырышлы итәргә сәләтле. Тулып пешкән җиләк-җимешләрнең өлгергән чагы һәркемгә муллык бирә.

Һәркемгә рәхәтлекне, табигатькә соклану мизгелләрен тоеп яшәргә язсын иде. Ә кешенең максаты: шушы гүзәллекне саклап, яшәртеп яшәү.

Саф җилләр сыйпасын чәчемнән,
Саф һава аллатсын битемне,
Юлымда чирәмнәр үссеннәр,
Кешеләр, саклагыз җиремне!



**Зөһрә Рәхиева, 11 нче “В” сыйныфы**



# Ә сез, беләсезме?



**Кайсыгыз тизрәк җавапларын таба!**

**1. Сүзнең башын мин әйтәм, ахырын сез әйтегез:**
Ак- (-кош,-бур, -ча, -чарлак, -май)
Ал-(-ма, -магач, - -ка, -тын)
**"Алты ат" :**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | а | т | | | |
| | а | т | | | |
| | | | а | т | |
| | а | т | | | |
| | а | т | | | |
| | а | т | | | |

(Хата, батыр, нарат, катык, сатучы, шатлык)



**2. Балалар фольклоры. Үртәвечләр:**
Азат, Азат, димәгез,
Аңа ипи бирмәгез.
Ашамасын, эчмәсен,
Укуыннан качмасын.

Арыслан, Арыслан,
Аш пешергән арыштан.
Пешерер иде бодайдан,
Сорамаган ходайдан.

**3. "Сүз эчендә сүз". Бу сүзләр эчендә нинди сүзләр яшерелгән?**
Аккош, акбур, акчарлак, акыл, ашханә, аркан, ашъяулык, ата, абага, аучы, алтын, алмагач, атна, айгыр.

**4. "Кем күбрәк" бөтен сүзләрдә дә "с" хәрефе булырга тиеш:**
С – сакчы, салкын, ...
О – оста, остаз, ...
Р – рәис, рәсем, ...
А – абыстай, арыслан, ...
У – уйсызлык, усак, ...

**5. Башваткычлар:**
Сыер нигә мөгри? (Сөйләшә белмәгәнгә)
Кәҗә нигә сакаллы? (Сакалын кырдырмаганга)
Сүзне ничек укыйлар? (Сулдан уңга)



**6. Татарча цитаталар**

- Белемле булу гына җитми, аны куллана белергә дә кирәк. (Цицерон)
- Вак-төяк ярдәм итүләрдән баш тартма: зуррагына да сәләтле диярләр. (Эпикур)
- Дошманнан үч алуның иң яхшы ысулы - аңа охшамау. (Аврелий)
- Иң кирәкле белем - кирәксезне онытa алу белеме. (Антисфен)
- Акыллы кеше күңел ачу чаралары артыннан түгел, ә үзенә күңелсезлекләр китерми торган әйберләрне булдыру артыннан чаба. (Аристотель)
- Яхшы әйбер начарайса, ул бигрәк тә начар. (Аристотель)
- Тормышның кыска икәнен исеңдә тотып яшә. (Гораций)

**Мәгариф журналыннан**



# Мәктәп хәбәрләре...



## “Җырым белән җиңдем дошманны”

*Муса Җәлил – илебезнең горурлыгы*

15нче февраль көнне татар әдәбиятының күренекле шәхесе, бар дөньяга танылган каһарман Муса Җәлилнең тууына 107 ел булып узды. Әлеге



вакыйга уңаеннан “Татар теле айлыгы” кысаларында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Безнең 7м сыйныфы укучылары Муса Җәлилнең шигырьләрен укыдылар, шулай ук көйгә салынган җырлар башкардылар, документаль кинофильмнар карадылар. “Моабит дәфтәре”ндә теркәлеп калдырылган авторның “Вәхшәт” шигыре аеруча тетрәндергеч яңгырый.

**Илнур Нугаев,**
**7 нче “М” сыйныфы укучысы**

## Зур бәйрәм

Ватанны саклаучылар көне алдыннан мәктәбебездә зур кичә булды. Бу көнне 5 К, 6 К сыйныфы укучылары тантаналы вәгъдә – “Кадет



аны” бирделәр. Кадетлар өчен бу көн зур һәм мөһим бәйрәм булды. Бәйрәм көндә бу сыйныф укучылары диңгезчеләрнең ак формаларыннан иделәр. Аларның бәйрәмчә киенүләре күңелләрне куандырды. Алар үзләрен бик җитди тоттылар.

Спорт залында бәйрәмнең тантаналы өлеше булды. Укучылар зур дәрәҗәле хәрби кешеләр, диңгезчеләр алдында ант бирделәр. Ә соңыннан актлар залында кадетлар катнашында бик матур концерт булды. Алар җырладылар да, биеделәр дә. Сугыш ветераннарының чыгыш-котлауларын тыңлау да аларга бик күңелле булды. Хәрби ансамбльнең музыкаль чыгышы күңелләргә тирән үтеп керде.

Диңгезче-кадетларыбызның белемле, тәртипле, илебезгә тугры кешеләр булып үсүләрен телибез. Үз алларына, илебезне саклаучылар булырга телибез, дигән максат куйганнар икән, аларның хыяллары тормышка ашсын.

**7нче “Г” сыйныфы укучылары**

## Мәктәбебезнең сылу татар кызы

“Татар кызы – 2013” шәһәр конкурсының район турында безнең мәктәптән 11 нче В сыйныфы укучысы Рәхиева Зөһрә катнашты. Зөһрә – чибәр, акыллы, пөхтә, ярдәмчел, инсафлы һәм бик яхшы билгеләренә генә укучы кыз.



Конкурсның иҗади турында ул җырлау сәләтен күрсәтте, ә интеллектуаль турда “Табигать һәм кеше” темасына бик мәгънәле эссе сөйләде. Ул бу сынауларда уңышлы чыгыш ясады һәм икенче турга үтте.

Икенче турда Зөһрә үзе турында бик матур презентация күрсәтте; оста итеп, испан һәм татар биюләрен биеде. Аның “Әдрән диңгез” җырын башкаруы барыбызны да сокландырды. Зөһрә үзен тирән белемле, иҗади, сәхнә остасы икәнлеген күрсәтте.

Нәтиҗәдә, Зөһрә “Иң сылу кыз” номинациясендә җиңүче булды. Аның белән бергә сәхнәдә җырлаучы Алсу, Ралинә, биюче кызлар һәм чыгышларда катнашкан егетләребез дә канәгать булдылар.

**Алсу Садыйкова**
**9 нчы “В” сыйныфыукучысы**

## Теле барның – иле бар
## (21 февраль – Халыкара туган телләр көне)

Мәктәбебездә февраль аенда ***“Туган телләр”*** айлыгы үтте. Укытучыларыбыз һәрбер сыйныфта төрле-төрле чаралар үткәрделәр. Алар: әкиятләр , табышмаклар кичәсе, грамматик КВН, иншалар конкурсы, нәфис сүз осталары чыгышы, стена газеталары чыгару. Барлык төр чараларда да укучылар актив булдылар.

Февраль аен йомгаклап, “Иң матур тел – туган тел” дип



исемләнгән нәфис сүз осталары конкурсы үтте. Башлангыч сыйныф , 5-7 сыйныф укучылары катнашында үткәрелгән шигырь конкурсында укучылар шигырьләрне сәнгатьле укырга тырыштылар. Алар Габдулла Тукай, Хәсән Туфан һәм башка шагыйрьләрнең туган тел, туган ил, табигать, белем турында шигырьләрен башкардылар. 5 Г сыйныфы укучысы Ахмадуллина Алсу, үзе язган шигырьне укып, иҗади сәләте барлыгын күрсәтте. Конкурс ахырында иң яхшы сөйләүчеләргә грамота бирелде: 1 урын – Мотыйгуллина Гөлназ (5 М), 2 урын – Идрисов Радик (4 В), 3 урын – Вафина Элина һәм Гиматдинова Алсу (4 Г).

**Ралинә Хәкимуллина,**
**9 нчы “Г” сыйныфы укучысы**

# Укыган кеше хур булмас



## Туган йортым

Илебездә һәркем үзенең әби-бабасы, әти-әнисе, абый-апасы, эне-сеңлесе яшәгән бер ояны, куышны шулай атый. Ә илебез безнең – зур хәрефле Татарстан. Ул – татар иле. Татар халкы бу илгә, үзенең күршеләре итеп, рус, чуваш, мари, әрмән, үзбәк һәм башка күп милләт кешеләрен җыйган. Алар һәрберсе туганнардай дус, тату яшиләр.

Безнең туган йортыбызны әйтеп бетергесез матур табигать чорнап алган. Җәен хуш исле агач-куаклар, төрледән-төрле чәчәкләр, яшел бәрхет үләннәр – барысы да сокландыргыч күренеш. Көзге алтынсу агачлардан, җир өстенә җәелгән сары, кызгылт паластан, уттай кызыл тәлгәш-тәлгәш миләшләрдән күз алгысыз. Кышкы салкын һавалы, карлы-буранлы көннәр, җемелдәвекле җир өсте, шыгырдавыклы юллар безнең Татарстанда гынадыр. Язгы шарлавыклар, кояш җылысында гөлдер-гөлдер килгән кызыл тәпиле күгәрченнәр, көтү-көтү очып килгән канатлы дусларыбыз, шомырт,алмагач,сирень чәчәкләренең аткан чагы – алар безнең туган йортыбыздагы табигый гүзәллекләр.

Татарстаным чиксез зур минем. Анда бик күп авыллар, районнар, шәһәрләр бар. Һәрберсендә тормыш гөрләп бара.

Туган йортым бай минем. Санап бетергесез байлыкларны тырыш хезмәт халкым таба. Байлыкларыбызның иң зурысы – кара алтын. Илем белән, халкым белән горурланам мин.

Туган җирнең тапсыз битләренә
Язган сыман гаҗәп бер дастан,
Илһам белән,
ташкын дәртләр белән
Яңа тормыш төзи Татарстан!
(Ә. Ерикәй.”Татарстан”)

Мәңге яшәсен минем туган Татарстаным. Мин аңа зур уңышлар, якты, тыныч киләчәк телим. Халкым бәхетле булсын!

**Ләйсән Абдуллина,**
**10 нчы А сыйныфы**

## Яз килә, яз килә…

Яз килә, яз килә… Атлап килә, чабып килә, яшел итәкләрен туздырып, ашыга-ашыга килә ул безгә. Табигатькә яз килүдән кешеләрнең күзләрендә өмет чаткысы уяна, тормыш елгасы туктаган җиреннән тагын җанланып китә. Димәк, яз табигатькә генә түгел, ә табигать баласы булган кешеләргә дә тәэсир итә!

Умырзая чәчәге… Яз җиту белән иң беренче булып дөньяга күз сала. Яшәү чәчәге ул, тормыш символы.

**Илгиз Якубов,**
**5 нче “А” сыйныфы укучысы**

## 23 февраль—Ватан саклаучылар көне

Ватан ул бик гомумиләштерелгән сүз. Бу сүзне әйткәндә без туган җирне генә түгел, әти-әнине дә, балаларны да, гаиләне дә күз алдында тотабыз. Ә Ватанны саклаучылар дип сезне, кадерле ир-атларыбызны, дәшәбез. Әйе, тормышның иң кадерлеләре— туган җир, ата-ана, бала, гаилә иминлеге күз белән караганда тар гына тоелган сезнең җилкәләрегезгә салынган. Нинди зур җаваплылык.

Рәхмәт сезгә, шул җаваплылыкны үз өстегездә тоеп, Ватанны саклаучылар сафында булганыгыз өчен. Рәхмәт сезгә, безнең күңелләрдә ышаныч һәм тынычлык уятканыгыз өчен. Беркайчан да авырмагыз, сау-сәламәт булыгыз. Көчле иңнәр кулагәсендә без үзебезне һәрвакыт нык теракле, бәхетле кешеләр итеп тоярбыз.

Ватанны саклаучылар көне белән ихластан сезне тәбриклибез.

**Мөхәррирләр**

## 8 март — Халыкара хатын-кызлар көне

Әлеге бәйрәм—иң якты, матур бәйрәмнәрнең берсе. Язның беренче бәйрәме уңаеннан кояш кебек ягымлы, игелекле, аяз көн кебек якты күңелле, чәчәктәй гүзәл затларыбызга күңел түреннән чыккан ихлас котлау сүзләрен һәм иң изге теләкләребезне җиткерәбез. Ныклы сәламәтлек, бәхет, якыннарыгызның хөрмәтен һәм сөюен, иминлек, бөтен изге эшләрегездә яңадан-яңа уңышлар телибез!



**Мөхәррирләр**

## Онытылмас очрашу

25 нче гыйнвар көнне 78 нче мәктәпнең коррекцион сыйныфлары белән очрашуга, 1 нче каналда “Тавыш” исемле конкурсны җиңүче ТР атказанган артисткасы Динә Гарипова килгән иде. Барлык укучылар аны шатланып каршы алдылар. Динә Гариповага хөрмәт белән карау гына түгел, ә күзләрдә соклану хисе дә сизелде. Очрашуда балалар төрле сораулар бирделәр, фотага да төштеләр. Динә Гарипова җырлап җибәргәч, аның сихри, моңлы тавышына рәхәтләнеп китәсең.

Ахырда ул үзенең автогрофларын да өләште.

**Самат Сәмигуллин,**
**10 нчы «А» сыйныфы укучысы**



**Мөхәррирләр:** Л. Хәбирова, З. Рәхиева, Д.Вәлиева, Л. Садыков, Р. Идрисов, З. Ибрагимова.
**Консультант:** Л. И. Исмаилова

Мәктәбем минем

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139, тел./ факс 268-58-61
E-mail: school_7878@mail.ru, S78kzn@edu.tatar.ru